**УПРАВЛЕНИЕ ОБРАЗОВАНИЯ**

**ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

# ПРИКАЗ

**от . 01.2021 г.** **№**

**О проведении межрегиональной конференции имени Ризаэддина Фэхреддина для учителей родного языка общеобразовательных учреждений на платформе Zoom.**

Согласно плану работы управления образования на февраль месяц 2020- 2021 учебного года, в целях распространения положительного опыта работы по изучению наследия Ризаэддина Фэхреддина

п р и к а з ы в а ю :

1.Провести 5 февраля 2021 г. с 13.00 ч. на базе МБОУ « Нижнечершилинская ООШ» межрегиональную конференцию имени Ризаэддина Фэхреддина для учителей родного языка общеобразовательных учреждений на платформе Zoom.

2.Утвердить Положение о проведении межрегиональной конференции имени Ризаэддина Фэхреддина(далее Положение) ( Прложение№1).

3.Руководителям общеобразовательных учреждений довести до сведения учителей родного языка Положение.

4. Контроль за исполнением данного приказа возложить на Г.К. Урманову, заместителя начальника управления образования по учебно - методической работе.

Начальник МКУ «Управление образования»
ИКМО «Лениногорский муниципальный район» РТ В.С. Санатуллин

Исполнитель :
Г.К. Урманова
5-15-61

Приложение №1
к приказу управления образования
№______________ от_________________

**Мәшһүр галим һәм язучы Ризаэтдин Фәхретдин исемендәге**

**төбәк ара конференция**

## НИГЕЗЛӘМӘСЕ

### I. Гомуми нигезләмә

Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәренең мәгариф идарәсе, Татарстан Республикасы Лениногорск районы "Түбән Чыршылы төп гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет төп гомуми белем бирү учреждениесе белән берлектә Ризаэтдин Фәхретдин исемендәге төбәк ара гамәли конференция үткәрү тәртибен билгели. Конференциядә татар халкының әдәбияты һәм мәдәнияте үсешенә зур өлеш керткән Ризаэтдин Фәхретдиннең иҗади эшчәнлеге төрле юнәлешләрдә өйрәнелә һәм тикшерелә.

### II. Конференциянең максаты һәм бурычлары

Ризаэддин Фэхреддин мирасын укыту процессында куллану тәҗрибәсе белән уртаклашу, бөек шәхеснең нәсыйхәтләре аша халкыбызның милли үзенчәлекләрен, күркәм сыйфатларын, укучыларны өлкәннәр үрнәгендә тәрбияләүне, буыннар бәйләнешен тәэмин итү.

### III. Укуларда катнашучылар

Конференциядә гомуми белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучылары, сыйныф җитәкчеләре, 1-9 нчы сыйныф укучылары катнаша ала.

### IV. Конференцияне оештыручылар

**Лениногорск шәһәренең Мәгариф идарәсе.**

Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе "Түбән Чыршылы төп гомуми белем бирү мәктәбе".

### V. Конференцияне оештыру

Конференция ике этапта үткәрелә:

1. этап – әзерлек этабы
2. этап – төп этап.

**Әзерлек этабы –** гаризаларны һәм эшләрне кабул итү – **2021 елның 31 гыйнварына** кадәр. Килгән эшләрне оештыру комитеты составына кергән экспертлар тикшергәннән соң, икенче турда катнашучыларга чакыру хатлары җибәрелә.

**Төп этап.** Икенче турга узган укытучылар **5 нче февраль көнне 13.00 сәгатьтә** Лениногорск районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе “Түбән Чыршылы төп гомуми белем бирү мәктәбе”нә **ZOOM аша үткәреләчәк йомгаклау чарасына чакырыла.**

Йомгаклау чарасы барышында икенче турга үткән укытучылар үзләренең дәрес эшкәртмәләрен тәкъдим итәләр. Конференциядә, каралу предметы дип, катнашучыларның эш тәҗрибәсенә нигезләнгән дәрес яисә тәрбия чарасы эшкәртмәсен яклау санала.

**Конференция кысаларында түбәндәге юнәлешләр эшләячәк:**

■ “Гыйлемнән башка байлык, байлыктан башка гыйлем булмас”. (Татар теле һәм әдәбияты дәресләре эшкәртмәсе яисә сыйныф сәгате эшкәртмәсе), укытучылар өчен

■ “Игелек орлыклары чәчегез, бәхет игеннәре игәрсез”. (“Тәрбияле бала” хезмәте буенча рәсем бәйгесе, 1-4нче сыйныф укучылары өчен)

■ “Яшик әдәп - әхлак белән, көнебез үтәр имин” (Риза Фәхретдин нәсыйхәтләрен сәнгатьле сөйләү, сәхнәләштерү буенча видеоязма, 5-9 нчы сыйныф укучылары өчен)

---

## VI. Фәнни- гамәли эшләргә таләпләр

Конференциядә катнашу өчен, 2021 елның 31 нче гыйнварына кадәр shcool473@mail.ru электрон адресына:

1. **Гариза – заявка**

| | |
|---|---|
| Катнашучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (тулысынча) | |
| Эш урыны, вазифасы,сыйныфы | |
| Укытучы, укучы | |
| Адресы, телефоны | |
| E-mail | |
| Эш юнәлеше | |
| Эшнең темасы | |

2. **Педагогик тәҗрибә остаханәсе** “Гыйлемнән башка байлык, байлыктан башка гыйлем булмас”.

Дәрес яисә чара эшкәртмәсе түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

■ эш өске һәм аскы яктан – 2 см, сул – 3 см, уң – 1,5 см, Microsoft Word форматында, Times New Roman шрифты белән, 14 нче кегль, 1,5 ара (интервал) аша бит киңлеге буенча тигезләп, 1,25 мм кызыл юл калдырып, сүзләрне юлдан-юлга күчермичә, компьютерда җыелырга тиеш. Сылтамалар текст эчендә шакмак җәяләрдә китерелә

[1:182]. Кулланылган әдәбият исемлеге текст азагында алфавит тәртибендә бирелә. Эшнең исеме калын шрифт белән уртага языла, исеме астында бер интервал аша уртага юл хәрефләре белән авторның фамилиясе, фәнни дәрәҗәсе яки квалификациясе күрсәтелә. Инициаллар фамилия алдында күрсәтелә. Әгәр дә авторлар берничә икән, фамилияләр бер юлга языла. Алдагы юлда кыскартуларсыз оешма яки учреждение атамасы күрсәтелә. Методик эшкәртмә ФГОС таләпләренә туры килергә тиеш. Кушымталар (презентация, фотосурәтләр, схема-таблицалар) булуы хупланыла.

Икенче турга узган укытучылар **5 нче февраль көнне 13.00 сәгатьтә** Лениногорск районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе “Түбән Чыршылы төп гомуми белем бирү мәктәбе”нә **ZOOM аша үткәреләчәк йомгаклау чарасына чакырыла.**

Йомгаклау чарасы барышында икенче турга үткән укытучылар үзләренең дәрес эшкәртмәләрен тәкъдим итәләр. Конференциядә, каралу предметы дип, катнашучыларның эш тәҗрибәсенә нигезләнгән дәрес яисә тәрбия чарасы эшкәртмәсен яклау санала.

3. **Сынлы сәнгать** “Игелек орлыклары чәчегез, бәхет игеннәре игәрсез”.

Иҗат эшләре — jpg форматындагы рәсемнәр, темага туры килә торган эчтәлекле, төрле башкару техникасында (карандаш, фломастер, акварель, гуашь, май, пастель, тушь) башкарылган рәсемнәрнең скан-күчермәләре кабул ителә.

4. **Актерлык осталыгы** “Яшик әдәп- әхлак белән, көнебез үтәр имин”

**Видеоязмага булган таләпләр**: Бәйге эшләрен электрон адреска яисә Яндекс. Дискка урнаштырып, электрон адреска сылтамасын җибәрергә. Бәйге эшләре катнашучының башкару осталыгына, шулай ук чыгышның оригиналь булуыннан гыйбарәт. Дәвамы 3-4 минут.

Конференциягә башка конкурсларда, конференцияләрдә катнашып, призлы урын алган, матбугатта басылган эшләр кабул ителми.

Конференциягә материаллар татар телендә кабул ителә.

Күрсәтелгән вакыттан соңрак җибәрелгән яки куелган таләпләргә җавап бирмәгән эшләр кабул ителми.

## VII. Бәяләү критерийлары:

- чыгышлар яттан яки өлешчә сөйләнергә тиеш;
- теманың тулаем ачылышы;
- сөйләмнең аңлаешлы булуы, кыскалык һәм ачыклык, күргәзмәлелек;

- оригинальлек, заманчалык һәм чыгыш барышында информацион белем бирү ресурсларын нәтиҗәле куллану.

Йомгаклау өлешендә чыгыш ясауга 4-5 минут вакыт бирелә. Компьютер презентациясе, мультимедия технологияләрен куллану хуплана.

## VIII. Укуларны үткәрү тәртибе

Конференция түбәндә күрсәтелгән вакыт кысаларында үтә:

- гариза, эшләр **2021 елның 31 нче гыйнварына кадәр shcool473@mail.ru** электрон адресына җибәрелә.

Элемтә өчен телефоннар мәктәп 8(85595) 3-95-35

8917 866-23-19 (Муллагалиева Алсу Вил кызы – татар теле һәм әдәбияты укытучысы)

89871872135 (Зиятдинова Әлфия Фаләх кызы - тәрбия эшләре буенча директор урынбасары)

- **2021 елның 5 нче февраленда 13.00 сәгатьтә** Татарстан Республикасы Лениногорск районы “Түбән Чыршылы төп гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе бинасында **ZOOM аша үткәрелә.**

Адресы: 423296, Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Совет урамы, 25 йорт.

Электрон адрес: shcool473@mail.ru

Барлык конференциядә катнашучыларга шәһадәтнамә, җиңүчеләргә I, II, III Дәрәҗәдәге Дипломнар электрон почта аша тапшырыла.

Лист согласования к документу № 9 от 12.01.2021
Инициатор согласования: Урманова Г.К. Директор ИМЦ
Согласование инициировано: 12.01.2021 11:07

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Урманова Г.К. | | Согласовано<br>12.01.2021 - 11:07 | - |
| 2 | Санатуллин В.С. | | Подписано<br>12.01.2021 - 11:52 | - |